| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>РАИСА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>РӘИСЕ<br>**УКАЗЫ** |

**Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе турында» 2014 елның 25 февралендәге ПУ-217 номерлы Указы (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 22 ноябрендәге ПУ-1065 номерлы, 2015 елның 30 июлендәге ПУ-688 номерлы, 2017 елның 20 мартындагы ПУ-231 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге ПУ-459 номерлы, 2017 елның 14 октябрендәге ПУ-911 номерлы, 2019 елның 2 февралендәге ПУ-58 номерлы, 2020 елның 5 июнендәге ПУ-339 номерлы, 2021 елның 18 февралендәге ПУ-154 номерлы, 2021 елның 2 мартындагы ПУ-194 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 25 июлендәге 506 номерлы, 2024 елның 26 июлендәге 565 номерлы һәм 2025 елның 17 июлендәге 547 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Н.В. Бутаеваны, В.С. Семенованы, А.О. Хохоринны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Әманов Рөстәм Ринат улын – «Чит ил гражданнарын социаль һәм мәдәни адаптацияләү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы җитәкчесен (килешү буенча);

Демьянова Елена Владимировнаны – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасарын;

Нәүрүзов Нәсими Гафиз улын – Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе структур бүлекчәсе җитәкчесен (килешү буенча);

Таҗетдинова Клара Алексеевнаны – Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасарын.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2026 ел, 20 февраль
№ 153